ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» гыйнвар 2022 ел № 05

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 28 декабрендәге 461 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары нигезендә, кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 28 декабрендәге 461 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле беренче абзац өстәргә:

««Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында түбәндәге мәгълүматны урнаштырырга:

- Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан бирелүгә планлаштырыла торган субсидия турында;

сайлап алуны уздыру турында игълан итү турында;

- сайлап алуда катнашучылар биргән тәкъдимнәрне (гаризаларны) карау

нәтиҗәләре турында;
- сайлап алу нәтиҗәләре турында.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 28 декабрендәге 461 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү буенча комиссия составы яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетынын 28.11.2019 № 461
карары белән расланган
( 12.01.2022 № 05 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппаратын сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Акбашев А. Э. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе-комиссия рәисе |
| Шәрипов Р.Р. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары-комиссия рәисе урынбасары |
| Егорова О.В. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы-комиссия секретаре |
| Зарипов А.А. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килештерү буенча) |
| Гатауллин Д.Г. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча) |
| Бадахшин А.Н. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килештерү буенча) |